**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы**

# КАРАРЫ

2022 елның 28 июненнән № 56

Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләргә хезмәт өчен түләү турындагы нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга субвенцияләр турында» 2006 елның 29 апрелендәге 258 номерлы карары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 53 статьясы, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 144 статьясы, «Россия Федерациясе Хәрби Көчләренең гражданлык персоналы (хезмәткәрләре) хезмәте өчен түләү системасы турында» РФ оборона Министрының 2019 елның 18 сентябрендәге 545 номерлы боерыгы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советы КАРАР ЧЫГАРДЫ:

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу белгечләренең хезмәте өчен түләү турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карар 2022 елның 1 июненнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Карамалы авыл җирлеге Советының «Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләргә хезмәт хакы турында нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 15 ноябрендәге 87 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Кама Тамагы муниципаль районы<br>
Олы Карамалы авыл җирлеге Советы рәисе,<br>
Олы Карамалы авыл җирлеге башлыгы Э.И.Байдамшин

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Карамалы авыл җирлеге Советының 2022 елның 28 июнендәге 56 номерлы карарына 1 нче кушымта

**Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечләрнең хезмәте өчен түләү турында**

# НИГЕЗЛӘМӘ

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Нигезләмә хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирлекнең хәрби-исәп хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү тәртибен җайга сала.

2. Әлеге Нигезләмә хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы хәрби исәпкә алу буенча белгечнең хезмәт хакын билгеләгәндә кулланыла.

3. Хәрби-хисап хезмәткәренең хезмәтенә түләү фонды, җирлеккә тапшырыла торган федераль бюджеттан субвенцияләр күләменнән чыгып, календарь елга төзелә.

4. Өстәмәләр күләме хезмәт өчен түләүгә бүлеп бирелгән акчалар чикләрендә билгеләнә.

## II. Хезмәт өчен түләү тәртибе һәм шартлары

1. Хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алуны гамәлгә ашыручы белгечләрнең хезмәте өчен түләү әлеге Нигезләмә нигезендә башкарыла һәм айлык вазыйфаи окладтан (алга таба - вазыйфаи оклад), компенсация түләүләреннән һәм кызыксындыру характерындагы түләүләрдән тора.

2. Икенче эш урыны буенча (мәшгуль)хәрби исәпкә алу белән шөгыльләнүче хезмәткәрләр өчен эш антасы сәгате хәрби исәптә торучы гражданнар санына туры пропорциональ рәвештә билгеләнә.

3. Хәрби-хисап хезмәткәренең вазыйфаи оклады күләмен инспектор окладына тиңләштерелгән окладтан «Россия Федерациясе Хәрби көчләре хәрби хезмәткәрләренең (хезмәткәрләренең) һәм хәрби частьләр оешмаларының

гражданлык персоналының (хезмәткәрләренең) хезмәтенә түләү системасы турында» РФ оборона министрының 2019 елның 18 сентябрендәге 545 номерлы боерыгы нигезендә билгеләргә.

| | |
|---|---|
| | Вазыйфаи окладның күләме, сум. |
| Хәрби-хисап хезмәткәре белгече | 6 840,00 |

4. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 282,284,285 статьясы нигезендә икенче эш урыны буенча (мәшгуль) хәрби-хисап хезмәткәренең вазыйфаи окладының максималь күләме азат ителгән хәрби-хисап хезмәткәренең вазыйфаи окладының 50%ыннан арта алмый. Икенче эш урыны буенча (мәшгуль) хәрби-хисап хезмәткәренә, хәрби исәпкә алынган гражданнар санын исәпкә алып, түбәндәге вазыйфаи окладлар билгеләнә:

- хәрби хисапта 400 гражданга кадәр булганда - азат ителгән хәрби-учет хезмәткәренең хезмәт хакының 40%ы.

5. Хезмәткәргә түбәндәге түләүләр каралган:

а) түбәндәге күләмнәрдә тиешле елларны эшләгән өчен вазыйфаи окладка ай саен өстәлә:
1 елдан артык - 5 процент;
2 елдан артык - 10 процент;
3 елдан артык - 15 процент;
5 елдан артык - 20 процент;
10 елдан артык - 30 процент;
15 елдан артык - 40 процент.
Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә билгеләү хокукын бирә торган эш стажын исәпләгәндә исәпкә алына торган чорлар календарь исәпләүдә билгеләнә һәм кушыла. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә акча алу хокукын бирә торган эш стажын (хезмәт) билгеләү өчен төп документ булып хезмәт кенәгәсе (хәрби билет) тора. Эшнең (хезмәтнең) стажын раслап, шулай ук тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә түләү алуга хокук бирә торган эш (хезмәт) стажы булуын раслый торган башка документлар да тапшырылырга мөмкин. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәләр әлеге өстәмәнең күләмен билгеләү яисә арттыру хокукы барлыкка килгән вакыттан билгеләнә һәм түләнә.
Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмә күләмен вакытында яңадан карау өчен җаваплылык кадрлар эше өчен җаваплы хезмәткәргә йөкләнә. Тиешле еллар эшләгән өчен айлык өстәмәне билгеләү оешма җитәкчесе боерыгы белән рәсмиләштерелә;

б) вазыйфаи бурычларны намус белән башкарган өчен елга ике вазыйфаи оклад исәбеннән акчалата бүләк.

Вазыйфаи бурычларны намус белән үтәгән өчен бер тапкыр акчалата түләү ай саен яисә календарь ел нәтиҗәләре буенча тиешле еллар эшләгән вакытка пропорциональ рәвештә түләнергә мөмкин. Ел нәтиҗәләре буенча бүләкләүне түләү өчен оешма җитәкчесенең боерыгы нигез булып тора;

в) махсус климат шартлары булган җирлекләрдә эшләгән өчен айлык түләү. "Россия Федерациясе Кораллы Көчләре оешмаларының гражданлык персоналына (хезмәткәрләренә) хезмәт өчен түләү системасы турында" РФ оборона министрының 2019 елның 18 сентябрендәге 545 номерлы боерыгы нигезендә Татарстан Республикасы өчен район коэффициенты күләме 1,15 тәшкил итә;

г) хезмәт өчен түләүнең расланган фонды чикләрендә хезмәткә түләү фондын экономияләү хисабына федераль законнарда һәм Россия Федерациясенең башка хокукый актларында каралган башка түләүләр (премияләр, матди ярдәм һәм башка стимуллаштыручы түләүләр). Эш нәтиҗәләре буенча премияләр һәм башка стимуллаштыручы түләүләр оешма җитәкчесе боерыгы нигезендә түләнә.

**III. Хәрби исәпкә алу буенча белгечкә чираттагы ял(отпуск).**

Хәрби исәпкә алу буенча белгечкә ел саен дәвамлылыгы 28 календарь көнгә тигез түләүле чираттагы ял бирелә. Икенче эш урыны буенча (мәшгуль) белгечләр өчен еллык түләүле чираттагы ял төп эшчәнлек буенча чираттагы ял белән бер үк вакытта бирелә.